АТЛАРЫМ — КАНАТЛАРЫМ*



АТЛАРДА ЧАБЫП КЫНА...
Республикада ат спортын үстерү проблемалары

Бер узган елда гына да журналист сукмаклары кайларга гына әйдәмәде дә, кайларда гына йөртмәде: Мәскәү, Уфа шәһәрләре, республикабыз район үзәкләре һәм авыллары: Актаныш, Лениногорск, Әлмәт, Минзәлә, Зәй, Чүпрәле, Чаллы...

Шулайрак туры килде — һәр җирдә мин ат ярышларын кararга яки атка бәйләнешле истәлекләрне тыңларга тырыштым. Актаныш якларында ат чабышлары Сабан туеның үзәгендә булды. Башкортстанда чагында яшь язучы Тайфур Сәгыйтов миңа республикада уздырыла торган атлы-спорт агитпоходының әһәмияте, анда катнашучыларның күпкырлы хәрби-патриотик эш алып барулары турында сөйләде.

— Ил төкерсә, күл була, — дип башлады ул сүзен. — Авыл саен берәмләп җыелган атлардан район үзәгендә зур гына отряд барлыкка килде. Ә бит дәһшәтле сугыш елларында да нәкъ шулай булган: һәр авылдан диярлек район үзәгенә атлар китерелгән, зур

* 1970 елда «Ватаным Татарстан» газетасында бастырылган ат спорты үсешенең проблемалары «Гасырлар авазы — Эхо Веков» журналының узган елдагы санында, мәкаләләр тупламы ярдәмендә бирелгән иде.

булмаган митинг уздырылган һәм халык юлга чыккан. Ике буын кешеләренең сәяхәтендә гади охшашлык күренә. Әмма зур аерма барлыгын да истән чыгарырга ярамый: сугышка китүчеләр, атка атланып, кулларына корал алганнар, ә җитмешенче еллар комсомолецлары, атка атланып, кулларына китап алдылар — агитпоходка чыктылар.

Әле күптән түгел генә шундый походны Казан шәһәренең Н. Э. Бауман исемендәге ветеринария институты студентлары да оештырды.

Атка атланып алар Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе районнары аша уздылар, кызыклы очрашулар оештырдылар, комсомол узган данлы юл турында сөйләделәр, Бөек Җиңүнең 30 еллыгына багышлап җырлар башкардылар, шигырьләр укыдылар.

Шуңа охшашлы атлы эстафета ярышларын, Сабан туйлары башланганчы, Куйбышев районында да үткәрергә исәп тоталар. Димәк, ат спорты күпмедер дәрәҗәдә Татарстан җирендә үзенчә яңарыш таба, яшел урам сорый.

Чыннан да, соңгы вакытларда безнең ат ярышларын онытып җибәрүебез, кайбер төбәкләрдә Сабан туе программаларыннан ат чабышларының төшеп калуы күңелне бик борчый иде. Алай гына да түгел, РСФСР халыкларының VI җәйге Спартакиадасында спортның шушы төре буенча чыгыш ясамаган өчен республикабыз командасы әллә никадәр очко югалтты. Сәбәп нәрсәдә соң? Мөмкинлекләребез юкмы? Алай дип әйтү хата булыр иде. Татарстанда менә дигән юртаклар әзерли торган махсус хуҗалыклар бар. Республикабызда үстерелгән юртакларның Бөтенсоюз һәм халыкара ярышларда приз алуларын да беләбез без.

Атлар, атлар! Бәп-бәләкәй чагыннан ук алар безнең күңелгә бихисап язчылар, шагыйрьләр әсәрләре аша кереп калган. Без үзебез дә атка атланып, тай көтүләре саклап үскән малайлар. Һәм шуңа күрә дә атлар, тайлар-колыннар турында язылган әсәрне дулкынланмыйча укып булмый. Менә Г. Ибраһимовның мәшһүр «Алмачуар»ыннан бер өзек:

«...Колын чыннан гаҗәеп бер нәрсә иде: аның ботлары ничектер җиңел атлыйлар. Бәкәлләре озын, шундый нечкә озын ки, мондыйлар тик чабышкы атларда гына була диләр. Әле яңа гына кибеп килә торган койрыгы белән ялы, әз генә, кыска гына булсалар да, озаклап үреп, кабартып ясаган ефәк бәйләме кебек, үзеннән-үзе дулкынланып торалар. Түм-түгәрәк сырты өстеннән, нәкъ арка үзәк турыннан, бармак калынлыгы кара асма кебек булып, койрыктан ялга җиткәнче, кара ефәк йон сузылган. Озынча, акыллы башның киң маңгаендагы озын яра кашка — бу колынны мең миллион иптәшләре арасыннан бөтенләй аерып, матурлыгы белән ялгыз дип күрсәтәләр. Бөтен гәүдәсе... матур итеп, коелып ясалган. Шундый... сылу, шундый асыл сәяк булып яратылганнар.

...Ул, әкияттәге баһадир кебек, ай үсәсен көн үсә, үзе көннән-көн матурлана, асыллана бара. Хәзер авылда аңа тел тидергән кеше юк».

Ленин премиясе лауреаты Чыңгыз Айтматовның «Бәхил бул, Гөлсары» повестен укып кемнәр генә сокланмагандыр.

Гражданнар сугышы каһарманы Чапаев һәм Буденый атлылары, Бөек Ватан сугышы елларында генерал Шәйморатов кавалеристлары даны еракларга таралды.

Бөек Җиңүнең 30 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә ат һәм сугышчы образы яңа ягы без күз алдына килеп баса. Яу кырында үлеп калган сөекле шагыйребез Фатих Кәрим үзенең «Пионерка Гөлчәчәккә хат» дигән поэмасында, халык мәкалендә әйтелгәнчә, «Ир канаты ат булыр» дигән фикерне алга сөрә.

Әйе, ат спорты көчлеләрне, тынгысызларны ярата. Спортның бу төрен массовыйга әйләндерү өчен булган тәҗрибәне уртак хәзинә итү, Казан дәүләт педагогия институтының физик тәрбия факультетында яки яңа ачылган Волгоград физкультура институтының Казан филиалында, булмаса, Әлмәт физкультура техникумында, һич югында, берәр авыл профессиональ-техник училищесы каршында тренер-наездниклар әзерләүче махсус бүлек ачу да үзен аклар иде. Бу хакта спорт белгече Д. Шәрәфетдинов моннан берничә ел элек матбугатта язып чыккан иде инде. Әмма ТАССР Министрлар советы каршындагы физкультура һәм спорт комитеты да, «Урожай» ирекле спорт җәмгыятенең Татарстан советы да, ни өчендер, бу мәсьәләдә активлык күрсәтмиләр. Югарыда искә алынган уку йортлары да бу юнәлештә конкрет эшкә керешкәннәре юк әле.

Инде Казан ипподромы хакында да берничә сүз. Дөрес, хәзер ул, ипподром дип түгел, ә Казан ат заводының күнегүләр уздыру мәйданы гына дип йөртелә. Хәер, эш исемдәмени!

Хикмәт массовый ат ярышлары уздыру урынының әрәмгә ятуында, разрядлы спортчылар, мастерлар әзерләргә мөмкин булган ат заводының республикабыз спорт оешмалары игътибарыннан читтә калуында.

Заводның баш зоотехнигы, ат спорты буенча берничә ел рәттән Идел буе чемпионы исеменә лаек булган Җәүдәт Хәбибуллин бу хакта үзе менә болай ди:

— Ат спортын үстерү кирәклеге бәхәссез. Бу хакта республика спорт комитеты да, «Урожай» ирекле спорт җәмгыятенең Татарстан советы да, ветеринария институты җитәкчеләре дә беләләр. Еш кына: «Эшлибез аны, булдырабыз аны» дип вәгъдә дә бирәләр. Әмма вәгъдә һаман да вәгъдә булып кала. Аптырагач, завод базасында ат спорты секциясен үзебез оештырдык. Хәзер анда 15 ләп егет шөгыльләнә. Тик бу безнең республика өчен диңгездәге бер тамчы кебек кенә...

Чемпион сүзләрендә хаклык зур. Элек, мәсәлән, республика ипподромы каршында ат спорты буенча махсус мәктәп эшләгән. Бүген аны «Урожай» ирекле спорт җәмгыяте үз карамагына ала алыр иде. Ә теләк булганда, «Урожай» җәмгыятенең Татарстан советы бу эшне үрнәк итеп оештырырга сәләтле. Мисал өчен, нәкъ менә Тәтеш спорт мәктәбе базасында тәрбияләнгән «Урожай» мәргәннәре бүген Татарстаныбыз данын бөтенсоюз һәм Европа чемпионатларында яклап призлы урын яуладылар. Бу эшне җайга салуда бары тик бердәй кызыксынучы оешмаларның конкрет эше, инициативасы гына кирәк.

Халык яратып карый торган ат спорты яшел урам сорый. Сабан туйларындагы стартлар чемпионатларга барып тоташсын иде.

С. Хәйретдинов.

Социалистик Татарстан. – 1975. – 17 май.

АТ ТУРЫНДА КАЙБЕР УЙЛАНУЛАР

Атлар турында язарга утырганчы гражданнар сугышы елларында туган «Комсомолка Гөлсара» җыры искә төште. Бу җыр алмачуар атка атланып дошманнарны кыйнарга китүче кыз турында. Хәер, атлар турында җырларны, бәетләрне, әкиятләрне бергә тупласаң, калын-калын томнар чыгар иде. Бу игелекле хайваннар элек-электән үк кешенең аерылмас дусты, тугры булышчысы булганнар. Колхозлашу елларында атлар төп эшче



көч иде. Алар белән туфрак эшкәрттеләр, чәчү чәчтеләр, ашлык урдылар. Ат илне саклауда катнашты. Гражданнар сугышының легендар тачанкаларын кемнәр генә белми? Бөек Ватан сугышы елларында махсус атлы армияләр оештырылды. Атлар Эльба суын эчтеләр. Кеше үзеннән соң килгән буынга атларга мәхәббәтне күчереп килгән.

Хәзер атом һәм ракета, автоматика һәм кибернетика заманында яшибез. Ләкин атлар һаман да безнең аерылмас юлдашларыбыз булып кала. Алар, хуҗалык эчендә тавык чүпләп бетермәслек эшләр башкару белән бергә, тормышыбыз хозурлыгы да! Әйтик, чабыш атлары, юртаклар катнашмаган кайсы Сабан туйның яме бар? Ә хәзерге көндә безнең колхозларның кайберләрендә генә бәйгеләрдә тартышырлык юртаклар калды.

Юртаклар турында артык җәелеп тә тормастан, хәзер гади эш атлары да азаеп бара. Менә мисал. Район статистика идарәсе мәгълүматларына караганда, 1973 елның 1 октябренә район хуҗалыкларында барлыгы 572 бия ат булса, быелның 1 июленә алар 495 башка калган. Ике ел эчендә «Гигант», «Урал», «Әсәнбаш», «Рассвет» колхозларында 8-10 башка бияләр кимегән.

Кайчандыр һәр хуҗалыкның көтү-көтү шаян колыннары, койрык чәнчеп чабучы җитез тайлары була иде. Хәзер алар бармак белән генә санарлык. Быелның 8 аенда 495 биядән нибары 178 колын гына алынган. «Заря», XXI партсъезд исемендәге, «Заветы Ильича», «Ударник», «Гигант», «Таң» колхозларында бияләрнең күп өлеше ел саен кысыр кала. Ә «Правда» һәм «Татарстан» колхозларында быел туган колыннар учетка да алынмаган. Ә колыннарның күпмесе исән кала? Бу хакта колхозларның үзендә дә, авыл хуҗалыгы идарәсенең зоотехника бүлегендә дә бер нинди мәгълүмат таба алмыйсың. Күрәсең, моны артык эш дип карыйлар.

«Заветы Ильича» колхозында булганда зоотехниклардан (биредә алар өч кеше):

— Сездә иң яхшы ат караучы кем? Ул күпме колын алып үстерде, аның хезмәтенә ничек түләнә? — дип сорау бирдек. Белгечләр иңбашларын җыерып, аптырашта калдылар. Бу факт үзе үк ат үрчетү, аннан файдалануның ни хәлдә икәнен ачык күрсәтә.

Ат абзарларына күз төшерик. Һәркайда диярлек башка терлекләрдән калган абзарларга атларны ябалар. Ремонтлау өчен чират аларга иң соңыннан җитә. Күп вакыт ремонтланмыйча да кала «Татарстан» колхозының Мәмәшир бригадасында ат абзары ярым җимерек хәлдә, стеналарыннан, тәрәзәләреннән җил сызгыра.

Куәтле техника белән бергә, җанлы тарту көченнән дә нәтиҗәле файдаланырга кирәк. Ямьле Сабан туйларын тагын да бизәп торучы чаптарлар, авыр йөкләрне саз-пычраклардан ыргылып тартып чыгаручы көчле бахбайлар күбрәк булсын иде. Ат гомер-гомергә кешенең дусты булды һәм шулай булып калачак. Димәк, бу тармакка да игътибар кимемәскә тиеш.

Н. Шәрифуллин.

Социалистик Татарстан. – 1975. – 30 сентябрь.

ҺӘР ЯКТАН ФАЙДАЛЫ

Республикада ат асрау мәсьәләләре белән кайбер хуҗалык җитәкчеләре генә түгел, зооветеринария белгечләре дә кызыксына. Мөслим районының «Урожай» колхозында, мәсәлән, нәселле ат фермасы бар. Аны булдыруда, элеккеге хуҗалык җитәкчесе Миргазиян Сәлахов белән бергәләп, элеккеге зоотехник Зөфәр Солтанов та зур эш күрсәтте. Азнакай районының «Әсәй», Әлмәт районының Токарликов исемендәге совхозларында, әнә шундый бердәмлек белән, ат фермаларын әйбәт оештырдылар.

Кукмара районының «Восток» колхозындагы Түбән Шәмәрдән бригадасы ат караучысы Фәйзелхак Галиуллинның хезмәте игътибарга лаек. Ул гарәп чабышкылары һәм першерон йөк атлары карады. Шул чабышкылар белән авыл егетләре ярышларда беренчелекне алып килде. Ләкин соңрак куелган җитәкчеләр нәсел фермасын бетерергә дигән карарга килгәннәр. Иптәш Галиуллин, ничек итсә итеп, атларны саклап калган. Миңа былтыр ул колхозда булырга туры килде. Җитәкчеләрнең атка карашы үзгәргән.

Ипподром булдырырга исәпләре бар икәнлекне әйттеләр, атлар өчен күпьеллык үләнигеләчәк икән. Аннары атлар белән шөгыльләнү үрнәген башка колхоз-совхозлар белән уртаклашырга ниятлиләр. Тик менә шушы бай хуҗалыкта бахбайларның башактан башка ризык күрми башлавы, тайларга игътибар кимү, ашау җитмәгәч, ябагаларын коя алмаулары эшнең рәтен җибәреп өлгергән иде инде. Мондагы ферманың яңадан нәсел фермасы дәрәҗәсенә күтәрелүен телим мин.

Ә менә шул районның «Новая жизнь» колхозында бөтенләй бүтәнчә хәл; нәсел эшенең авыр йөк атлары белән алып барылганлыгы бахбайларның көчле гәүдәләреннән күренеп тора, алларына яхшы печән, силос, солы салына. Хуҗалык февраль аенда ук колын ала башлый икән. Удмурт Республикасыннан саф токымлы рус йөк атлары да алып кайтканнар. Колхоз рәисе Рәфикъ Рәүфов нәсел фермасы булдыру, ат симертү һәм кымыз ясауны җайга салу ягында. Тренер чакыртып, яшьләр белән күнегүләр оештыру турында да уй-фикере бар аның.

Сабан туйларның яме ат чабышыннан һәм милли көрәштән торганлыгын беләбез. Хәзер чабышкылар ярышы булмый да башлады... Ә күршебез Башкортостанда атка игътибар зуррак бит. Уфада бик яхшы ипподром төзеделәр, аның янында атлы спорт мәктәбе оешты. Азан ипподромы хәленә килсәк, аны яңарту-үзгәртү өчен проект эшләнсә дә, төзелеш өчен аларга акча бирмиләр...

Шуны әйтәсем килә: атларны алар өчен иң төп шартлар — әйбәт торак, яхшы азык булган хуҗалыкларда гына ишәйтү отышлы. Азнакай районындагы «Авангард» колхозының Күктәкә бригадасы атлар фермасын мисалга китерәм. Монда ат санын киметмиләр, чөнки аларга уңай шартлар булдырылган.

Алтмышынчы елларга кадәр атка җитди әһәмият бирелде. Ул чакта нәселсез атлар булмаган, хәзер нәселен белүче дә юк... «Авыл егетләре» ярышларын уздырганда чабышкыларның нәсел графасын тутыра башласак, төртелеп калабыз...

Республика хуҗалыкларының нәсел фермаларындагы айгырларны сатуда да тәртип урнаштырасы бар, югыйсә аптырашта калу очраклары булгалый. Татарстан дәүләт нәсел берләшмәсе дә бу юнәлештә булышлык итәргә тиештер ич?

Мөслим районындагы туган авылым Олы Чакмакка улым Ленар белән кайткалыйм. Монда җитәкчелекнең, белгечләрнең атларга карата гаме юк. Ат караучы Фәрит агай Шакиров аларга азыкны сорап-ялварып, гозер итеп кенә ала. Заманында Мөслим Сабан туенда беренчелекне алган чабышкылар шушында иде...

Җыеп әйткәндә, атчылыкка игътибар азайды. Бу тармакта эшне оештыру буенча тәҗрибә алмашулар да юк, семинар-фәлән үткәрелми. Казан ат заводы, Куйбышев районындагы «Татарский» ат заводы. Минзәлә һәм Чистайдагы дәүләт конюшнялары ни белән шөгыльләнә? — хәбәрдарлык юк. Мәсәлән, «Татарский» ат заводы орлов токымлы юртаклар үрчетә һәм һич тә мактанырлык нәтиҗәләргә ирешкәне юк.

Сбруйларга, арба-чанага кытлык булуы, аларны җитештерүнең бетүе күңелне хафага сала. Зур авылларда бу эшне торгызасы иде.

Атка да, ат караучыларга да, ат спорты белән шөгыльләнергә теләүчеләргә дә йөз белән борылу, аларга җитди игътибар бирү сорала. Республикабызда ат спорты федерациясен оештыру турында да ихластан кайгырта башларга бик вакыт инде.

Рөстәм Сәяхов, ат спорты буенча республика категорияле судья, ат спорты инструкторы. Әлмәт шәһәре.

Социалистик Татарстан. – 1975. – 4 июнь.

Язмалар ***Биктимер Сүнчәләйнең***
шәхси архивыннан тупланды.